**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«25» 12 2020 ел Яр Чаллы №4933

Иштирәк авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын эшли башлау турында

Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетының гаризасын карап, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32, 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документлары нигезендә техник регламентлар таләпләренә таянып алып барырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А. Р. Хәбибуллин